Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

04.11.2021 ел № 3

«Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең Иске Илтерәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең Иске Илтерәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Иске Илтерәк авылы, Ленин урамы, 71а йорт адресы буенча урнашкан, КФҮ бинасында билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең Иске Илтерәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Иске Илтерәк авылы, Ленин урамы, 71а йорт адресы буенча урнашкан, КФҮ бинасында билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең Иске Илтерәк авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:

1) Ленин ур., Мәктәп ур.;
2) Совет ур., Яшьләр ур., Бакча ур., Гагарин ур.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Иске Илтерәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме?:

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш капламалы поселок эчендәге юлларын чокырлы ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- кышкы чорда юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**3) КККны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- контейнерлар сатып алу, контейнер киртәләр төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**4) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**

- Иске Илтерәк авылында су үткәргеч челтәрләрен ремонтлау, суэтем башнясын койма белән әйләндереп алу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

**5) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү** (янгын сүндергечләрне, электр белән тәэмин итү челтәренә тоташтырылган яктылык күрсәткечләре сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм күргәзмәләрдә, белдерүләр такталарында элү юлы белән халыкка хәбәр итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы: С.М. Маклаков